| СОВЕТ ЛЕВАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕВАШЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.05.2020 с. Левашево № 137

**Үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендәге 1 пунктының 3 пунктчасының «б» абзацын үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә вазыйфаи затларның аерым категорияләренең катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 07 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә

**Левашево җирлеге Советы карар кылды:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 сентябрендәге 59 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен бушлай рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 18 июнендәге 102 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Левашево авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидова**